| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НИЖНЕУРАСПУГИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН УРЫСБАГА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31 январь 2025 ел.** Түбән Урысбага **№ 4**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карары нигезендә Башкарма комитет Түбән Урысбага авыл җирлеге КАРАР ИТӘ:

1. 2025 елның 01 февраленнән Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 9 165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Түбән Урысбага авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 01 февраленнән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2024 елның 09 февралендәге 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында .http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 01.02.2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Түбән Урысбага
авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Сибгатуллин..

1 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты
2025 елның 31 гыйнварындагы №4 карарына

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 01.02.2025 елга

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәтләр бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Каберне һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4 994,68 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1 422,81 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 747,88 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |

2 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Түбән
Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты
2025 елның 31 гыйнварындагы №4 карарына

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 01.02.2025 елга

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәтләр бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Тәннең киеме | 882,44 |
| 3. Каберне һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4 112,25 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1 422,81 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 2 747,87 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |